Салауат күпере журналына кушымта

Сыбыҙғы


№ 2



Сыбызгы-Йомран ничек итеп космонавт булган?

Сыбызгы мин, сызгырам,
Тәмле итеп сызгырам,
Ачы итеп сызгырам.
Җылак, кире кызларны
Һәм усал малайларны,
Тәртипсез балаларны
Ачуланам, кыздырам!
Мин –
Сыбызгы-Йомран!..

Алай гына түгел әле:
Мин – Очучы-Йомран!
Җир белән саубуллашам,
Ракетага утырам.
Киттек, әйдә, син дә утыр,
Айга меник, Марска,
Венерага.
Бер күреп кайтыйк әле,
Бер йөреп кайтыйк әле.



Бер мәртәбә сызгырган Сыбызгы-Йомран, ике мәртәбә һәм өченчесендә... тагын да катырак итеп сызгырган да Галәмгә очып киткән ди. Айга ук менеп утырган, йолдызларны чүпләп кесәсенә тутырган!

Әйдәгез, без дә Сыбызгы-Йомран артыннан галәмгә очыйк

Минем космонавт буласым килә. Ә синең космонавт буласың киләме соң? Килсә, әйдә, космик корабыңа утыр да минем арттан оч!

– Киттек!


– Поехали!

© "Сыбызгы", 2000 ел


Без очабыз да очабыз

Әнә, күпме планеталарны күреп уздык инде. Күрәсеңме, Кояш системасына кергән планеталарны!

Планеталарның күбесе грек һәм рим аллалары исеме белән аталып йөртелә.



Менә алар:



Әүвәл **Кояш** үзе

Без яшәгән **Җир** планетасы



Меркурий – канатлы Алла.

Венера – мәхәббәт Алласы.

Марс – сугыш Алласы.

Юпитер – аллаларның да Алласы.

Сатурн – Юпитерның әтисе.

Уран – Сатурнның әтисе.

Нептун – диңгез Алласы.


Плутон – җир асты Алласы.

Меркурий

Меркурий Кояшка иң якын булган планета. Аның өстендә ком һәм ташлар гына, су да, сулый торган һава да юк.

Меркурийда көндезләрен бик эссе була, төнлә исә, киресенчә, гаять салкын. Меркурий Кояшны 88 көн эчендә әйләнеп чыга.





«Маринер-10» космик аппараты Меркурий өстеннән очып, Җиргә аның ташлы өслеген төшергән фотосурәтен җибәрде.


Римлыларның Меркурий исемле аллалары булган. Ул канатлы башмаклары ярдәмендә бик тиз йөргән. Кояшны тиз әйләнеп чыгуы сәбәпле планетага да Меркурий дип исем кушканнар.



Егылып төшкән авыр метеоритлар Меркурий өстендә чокырлар, ягъни кратерлар хасил иткән.

Венера

Венера Кояштан икенче планета. Ул калын болытлар белән капланган. Планетада коточкыч эссе, хәтта бер дигәнче мичсез-нисез бәлеш пешерергә мөмкин.




Берничә автомат станция Венерага очып, әлеге планета хакында Җиргә мәгълүмат җибәрә. Аннан соң станцияләр эссегә түзә алмыйча сафтан чыгалар.

Венера күктәге иң якты планета булып исәпләнелә.



Венераның өсте сүнгән вулканнар белән капланган.

Марс



Марс планетасы кызгылт төсле булып күренә. Марста елга урыннарына охшаган ерганаклар бик күп, ләкин аларда су юк. Планета өстендә сүнгән вулканнар бихисап.



Элегрәк кешеләр Марста тере җан ияләре яши дип уйлаганнар һәм аларны «Марсианнар» дип атап та йөрткәннәр.

Юпитер

Юпитер Кояш системасындагы иң зур планета. Әлеге гаять зур шар сыеклык һәм газлардан тора.


Юпитер әйләнәсе буенча 16 иярчен оча. Аларның өчесе хәтта айдан да зуррак.



Юпитерның иң зур 4 иярченен Галилео Галилей ачкан:



Сатурн



Сатурн сыеклык һәм газдан торган бик зур шар. Җирдән караганда Сатурн ике киң боҗра белән уратылган кебек күренә.

Бу боҗраларның тагын меңнәрчә нечкә боҗрачыклардан торганы мәгълүм.

Сатурнның 18 иярчене бар.



Титан – Сатурнның иң зур иярчене. Аның өслеге газлар белән чолганып алынган.



Сатурнның һәр боҗрасы газлардан, боз кисәкләреннән тора.



Уран

Уран Кояш тирәли яны белән әйләнүче бердәнбер планета. Аны 11 нечкә боҗра һәм 15 иярчен чолгап алган. Уран яны белән торганлыктан Кояшка аның әле Төньяк полюсы, әле Көньяк ягы карый.

Болар Уранның иң зур 5 иярченнәре. Аларның иң зурысы Титания.


Миранда

Ариэль

Титания

Миранда белән Ариэль – Уранның ике иярчененең исемнәре. Бу атамалар В.Шекспир әсәрендәге геройлар исеме.

Нептун



Нептун сыеклык һәм газлардан торган гаҗәеп зур шар. Планета өстендә бик каты җил исә, ул җилнең тизлеге сәгатенә ике мең чакрымнан да артык китә.


Нептунның 8 иярчене бар. Аларның икесе генә Җирдән күренә.

Нептунның иң зур иярчене Тритонның өслеге бик зур ярыклары булган боз белән капланган.

Нептунны телескопсыз, ягъни гади күз белән генә Җирдән күреп булмый. 1846 елда астраномнар аны диңгез Алласы Нептун исеме белән атыйлар.


Плутон

Плутон – Кояштан иң ерак торучы планета. Плутонга автоматик станция җибәрелмәгәнлектән, галимнәр аның хакында бик аз беләләр.



Бәлкем, Плутоннан соң тагын берәр планета бардыр. Хәер, әлегә бу билгесез булып кала бирә.

Һәр 248 ел саен Плутон Кояшка якынлаша төшә.



Аның бердәнбер иярчене булган Харон Плутонга бик якын тора.



Укучым!

Син ничек уйлыйсың: Кояш системасында тагын берәр планета бармы икән?



Кометалар һәм метеорлар

Күк йөзендә кыска вакыт эчендә чагылып алган көчле яктылык метеор дип атала. Шул рәвешле галәм тузаннары Җир атмосферасында яна.


Астероидлар исә тау токымнарының бик зур кисәк-кантарлары. Кояш әйләнәсе буенча Марс белән Юпитер арасында миллионлаган астероидлар очып йөри.

Кометалар таш токымнарыннан, боз кисәкләреннән һәм тузаннардан тора. Кометалар Кояшка якынлашкан чагында аларның төтенләгән коерыклары хасил була.




Метеорларны башка төрле атылучы йолдызлар дип тә атап йөртәләр. Алар – астероид һәм комета кисәкләре.

Метеор Җир атмосферасына килеп керүгә шундук янып бетә. Күк йөзендә бер-ике секунд балкып ала.




Церера иң зур астероидлардан санала. Аркылыга аның буе 1000 чакрымга сузыла.



Комета төше

Кометалар пычрак кар катнашмасы белән укмашкан шар кебек. Кояшка якынайган чагында кар-бозлар эри һәм тузан белән газлардан койрык хасил була.

Җиргә егылып төшкән астероидны метеорит дип атыйлар. Шундый метеоритларның берсе моннан күп еллар элек Америка җиренә төшеп, гаҗәп зур чоңгыл хасил итә.



Астронавтлар

Галәмдәге тормыш җирдәгесеннән бик нык аерыла. Галәмдә һава да, авырлык та юк. Корабльдән галәмгә чыгу өчен космонавтлар скафандр кия һәм кислородлы баллоннар ала.


Космик корабльләрдә космонавтлар өчен яшәргә бөтен шартлар да тудырыла.

Галәмдә авырлык юк, шуңа күрә космонавтлар шар кебек очып йөриләр.

Скафандрсыз космонавт йә кояш нурларында пешәргә яки салкыннан бозланып туңарга мөмкин.

Космонавтлар галәмдә дә физик күнегүләр ясыйлар.

Йоклаганда космонавтлар йокы капчыкларын караваткa бәйләп куялар. Алайса йоклаган килеш очып йөрергә мөмкиннәр.








Ракеталар





Ракеталар галәмгә очу өчен файдаланыла. Алар ярдәмендә галәмгә автоматик станцияләрне алып чыгалар, шулай ук космонавт абый-апалар да нәкъ менә ракеталарга утырып оча инде.

Галәмгә очуларга Үзәк идарә җитәкчелек итә.

«Сатурн-V» галәмгә оча. Ракетаның озынлыгы 110 метр. Күп өлешенә ягулык тутырылган. Җиргә бары өч космонавт утырган җитәкчелек модуле генә кире әйләнеп кайта, калган өлеше янып юкка чыга.


Айга иң беренче булып Америка астронавтлары Нил Армстронг белән Эдвин Олдрин менәләр. Бу хәл 1969 нчы елның 20 июлендә була.

Галәмгә беренче очкан кеше – Юрий Гагарин. Бу 1961 нче елның 12 нче апрелендә була.

Телескоплар

Ерак йолдыз һәм планеталарны күзәтү өчен галимнәр телескоплардан файдаланалар. Алар махсус линзалар һәм көзгеләр ярдәмендә ясала.

Тикшеренүләр өчен шулай ук радиотелескоплардан да файдаланалар. Чөнки кайбер галактикалардан радиосигналлар чыгып тора. Радиотелескоплар ярдәмендә аларны кабул итәргә мөмкин.




Киләчәктә, бәлки, астронавт галимнәр башка планеталарда яшәүче кеше кебек акыллы затларның да радиосигналларын тота алырлар әле.



Бу гаять зур телескоп Калифорниядәге Паламор дигән тау башына урнаштырылган. Ул диңгез тигезлегеннән 2000 метр өстә.






«Хаббл» дип аталган космик телескоп.



Дөньядагы иң зур телескоп «Арекина» дип атала. Ул Пуэрто-Рикода урнашкан.



Австралиядәге бу радиотелескоп күкне игътибар белән күзәтеп, тыңлап тора.

Хөрмәтле өлкәннәр!
Кадерле әти-әниләр!

Берәүгә дә яңалык түгел: без хәзер куәтле техника заманасында яшибез. Күрәк һәм сәнәк белән генә бик еракка китеп булмый.

Тормышыбызга компьютерлар килеп керде. Ләкин алар белән эш итәргә бары тик балачакта гына өйрәнергә мөмкин. Буыннар каткач,соң була инде ул.

Без шуларны уйладык-уйладык та «Сыбызгы» битләрендә балалар өчен компьютер уеннары тәкъдим итәргә булдык.

Компьютер өегездә булмаса, хәзер алар мәктәпләрдә бар инде. Балаларга аның уеннарын тәкъдим итсәк, әлбәттә, һәркем дә компьютер белән кызыксынып китәчәк!

«Сыбызгы»ның һәр саны балагызның кулында булсын!

Аны алдыру өчен «Салават күпере»нә язылу да бик җиткән,ягъни аерым язылып торасы юк.

«Сыбызгы».

Кадерле укучыбыз!

«Сыбызгы»ның алдагы санында без Шакмай атлы малай турындагы хикәятне дәвам итәргә тәкъдим иткән идек. Шулай ук «Салават күпере» аша кызыклы сорау-табышмак та биргән идек. Журналханәгә бик күп хатлар килде. Без аларны игътибар белән укып чыктык һәм җиңүчеләрне ачыкладык.

Менә кемнәр алар безнең җиңүчеләребез:

Илсөя Хисамова (Тәтеш)
Булат Сәетгалиев (Башкортостан)
Эльвира Зөбәерова (Башкортостан)
Айсылу Гарипова (Казан)
Гүзәл Галимова (Саба)
Рәмиз Зарипов (Балтач)
Алсу Хисамиева (Кукмара)
Алинә Шәрәфиева (Яшел Үзән)
Артем Белов (Башкортостан)
Илнур Шәвәлиев (Сарман)
Адель Җамалиев (Яшел Үзән)
Айгөл Нуриева (Мамадыш)
Айдар Сәгъдиев (Арча)
Әлфия Зартдинова (Чүпрәле)
Флүзия Баһаутдинова (Кама Тамагы)
Раилә Габитова (Буа)
Зилә Хөснетдинова (Түбән Кама)
Лариса Минһаҗева (Балык Бистәсе)
Дамирә Җәләлова (Апас)
Динар Мөхәммәтҗанов (Башкортостан)
Эльвира Гайнетдинова (Баулы)
Раилә Мөэминова (Балтач)
Айзат Әхмәтҗанов (Әтнә)
Рузия Нәбиуллина (Апас)
Рузилә Фәтхуллина (Әгерҗе)
Лилия Локманова (Чирмешән)
Руфинә Сафиуллина (Зәй)
Энҗе Камаева (Әгерҗе)
Альбина Сәфәрова (Сарман)
Алисә Хәсәншина (Түбән Кама)
Руслан Халиков (Сарман)
Ильвира Харисова (Азнакай)
Эльвира Әхмәтшина (Сарман)
Рифә Хәмидуллина (Башкортостан)
Петя һәм Коля Минкиннар (Чистай)
Гөлнара Бариева (Балтач)
Лилия Җаббарова (Чистай)
Динара Шаһиева (Түбән Кама)
Рәис Нигъмәтуллин (Яшел Үзән)
Фәридә Гарифуллина (Башкортостан)
Ринат Йосыпов (Башкортостан)

Җиңүчеләребезне чын күңелдән котлыйбыз!
Безнең белән бергә булыгыз!
Уңышлар Сезгә!!!



Сыбызгы

2 – 2000

«Салават күпере» журналына кушымта

Баш мөхәррир **Зиннур ХӨСНИЯР**
Баш мөхәррир урынбасары Вакыйф НУРИЕВ
Бүлек мөхәррире Ләбиб ЛЕРОН
Бизәлеш мөхәррире Фәрит МУЛЛАХМӘТ
Компьютер дизайны Мөнирә КУЗИЕВА
Исәп-хисап бүлеге Рәмзия САЛИХ

Редакция адресы: 420012 Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14нче йорт.
«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды
һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 19.5.2000 ел. Басарга кул куелды 19.5.2000 ел.
Тиражы 16264 данә. Заказ Э-218. Бәясе килешү буенча.